**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «20» апреленнән № 33-261

2022 елдаТатарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкының гендер составын исәпкә алып кадрлар эшен оештыру һәм 2023 елга бурычлар турында мәгълүмат

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы кадрлар секторы мөдиренең 2022 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкының гендер составын исәпкә алып, кадрлар эшен оештыру һәм 2023 елга бурычлар турында мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советы кадрлар секторы мөдире А.А. Бочарованың 2022 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкының гендер составын исәпкә алып, кадрлар эшен оештыру һәм 2023 елга бурычлар турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарына 2023 елда һәм аннан соңгы елларда тәкъдим итәргә:

2.1. Кадрлар сайлаганда һәм урнаштырганда, шул исәптән кадрлар резервын формалаштырганда, 2021 елгы Бөтенроссия халык санын алуның милли күрсәткечләре нигезендә муниципаль берәмлек халкы составының барлыкка килгән балансын сакларга;

2.2. Муниципаль органнарның җитәкчелек составы һәм оешма буенча конкрет эш алып бару өчен 2021 елда Бөтенроссия халык санын алуның территориаль күрсәткечләреннән 7-8 % читкә тайпылуның рөхсәт ителгән чиген сакларга;

2.3. Депутатлар корпусы составларын формалаштыру эше өчен 2021 елда Бөтенроссия халык санын алуның территориаль күрсәткечләреннән тайпылу рөхсәт ителгән чиген 10 % дип билгеләргә;

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районы рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов